ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 декабрь, 2021 ел

№ 10/5

Товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 360-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясындагы 2 өлеше һәм 69 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/8 номерлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9, 2016 елның 24 февралендәге 6/7, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/8, 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/8, 2019 елның 7 октябрендәге 33/8 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 16 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Федераль законның 20 статьясы нигезендә сатып алулар буенча иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләре нигезендә заказчы тарафыннан кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру;»

2) 17 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3) 23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Заказчы контракт нигезендә тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү буенча аерым функцияләрне башкару, шул исәптән сатып алу турында документлар эшләү (Федераль закон тарафыннан сатып алу турында документлар каралган очракта), бердәм мәгълүмат системасында һәм электрон мәйданчыкта әлеге Федераль законда каралган мәгълүмат һәм электрон документлар урнаштыру, чакыруларны юллау, тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүгә

бәйле башка функцияләрне башкару өчен махсуслаштырылган оешманы җәлеп итәргә хокуклы. Шул ук вакытта сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия төзү, контрактның башлангыч (максималь) бәясен, бер данә товарның эш, хезмәт күрсәтүләрнең башлангыч бәясен, күрсәтелгән берәмлекләрнең бәяләренең башлангыч суммасын, контрактның предметын һәм башка мөһим шартларын билгеләү, контракт проектын, сатып алу турында документлар проектын раслау (Федераль законда сатып алу турында документлар каралган очракта) һәм контрактны имзалау заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге Карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев